КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 7 май г.Казань № 332

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип санау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары 2018 елның 1 июленнән үз көчен югалткан дип санарга:

«Татарстан Республикасы территориясендә катнаш эшкәртү режимында җитештерелә торган җылылык энергиясе җибәрүче «Таттеплосбыт» ачык акционерлар җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин ителә торган торак урыннарда яшәүче гражданнарга торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен гражданнарның түләве артуны киметүгә максатчан субсидия бирү турында» 2012 ел, 27 август, 738 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә катнаш эшкәртү режимында җитештерелә торган җылылык энергиясе җибәрүче «Таттеплосбыт» ачык акционерлар җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин ителә торган торак урыннарда яшәүче гражданнарга торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен гражданнарның түләве артуны киметүгә максатчан субсидия бирү турында» 2012 ел, 27 август, 738 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 ел, 19 ноябрь, 1013 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә катнаш эшкәртү режимында җитештерелә торган җылылык энергиясе җибәрүче «Таттеплосбыт» ачык акционерлар җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин ителә торган торак урыннарда яшәүче гражданнарга торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен гражданнарның түләве

артуны киметүгә максатчан субсидия бирү турында» 2012 ел, 27 август, 738 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 26 февраль, 122 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә катнаш эшкәртү режимында җитештерелә торган җылылык энергиясе җибәрүче «Таттеплосбыт» ачык акционерлар җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин ителә торган торак урыннарда яшәүче гражданнарга һәм «ТГК Уруссинская ГРЭС» ябык акционерлар җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин ителә торган торак урыннарда яшәүче Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу поселогы гражданнарына торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен гражданнарның түләве артуны киметүгә максатчан субсидия бирү турында» 2012 ел, 27 август, 738 нче карары белән расланган Гражданнарның торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләве артуны киметүгә максатчан субсидия турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымтага үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 12 май, 299 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 ел, 22 июнь, 412 нче.

2. 2018 елның 1 июле хәленә карата торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен гражданнарның түләве артуны киметүгә максатчан субсидия билгеләнгән затларга әлеге субсидия бирелү вакыты беткәнгә кадәр түләнелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Казан шәһәре һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлекләре, Зәй, Түбән Кама, Ютазы муниципаль районнары белән берлектә, бу карарны тормышка ашыру буенча халык белән аңлату эшен үткәрергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин